**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**от 10.08.2023**

**КАРАР**
**№ 1096**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МКУнә ведомство буйсынуындагы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашырган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрен аттестацияләү тәртибен раслау турында» 2023 елның 22 февралендәге 304 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләренә (директорларына, мөдирләренә) һәм җитәкчеләре (директорлары, мөдирләре) вазыйфаларына кандидатларга аттестация үткәргәндә бердәйлекне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Җитәкчеләр вазыйфасына кандидатларны аттестацияләү тәртибе буенча тәкъдим җибәрү турында» 2020 елның 31 декабрендәге 15237/20 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә ведомство буйсынуындагы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашырган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре (директорлары, мөдирләре) вазыйфаларына кандидатларны һәм җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитәкчеләрне һәм җитәкче вазыйфасына дәгъва кылучы затларны аттестацияләү алар белән хезмәт килешүе төзегәнгә кадәр, башка очракларда - хезмәт шартнамәсе шартлары белән хезмәткәр өчен билгеләнгән сынау срогы узганчыга кадәр башкарыла».

1.2. 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аттестацияләнүче «Мәгариф бүлеге» МКУнең күрсәтмә акты белән расланган графигы белән аны үткәрү срогы билгеләнә торган аттестациягә кадәр ике атнадан да соңга калмыйча күрсәтелгән тәкъдим белән таныштырылырга тиеш».

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин